**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

**2019 елның 18 ноябре** **№ 128**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендә кабул ителгән 61 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советы КАРАР чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендә кабул ителгән 61 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 статьяның 2 пунктында " (индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган)»;

5 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

6 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сайлап алынган җир участогы турында хәбәрнамә салым органына дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырылырга мөмкин.».

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы икенче абзацы 2020 елның 1 гыйнварыннан, әмма әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы Сөйки авылы, Красноармейская урамы, авыл үзәге;

- Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы Сөйки авылы, Колхоз урамы, китапханә бинасы;

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга .

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Сөйки авыл җирлеге башлыгы,**
**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Сөйки авыл җирлеге Советы рәисе** **В.П. Никитин**